## Мәхмүт ГАЗИЗОВ:

# “Йөрәк белән күпне күтәрдек”



*...Тәгәри китте йомгагым,*
*Йомгак түгел — җырларым,*
*Йомгак очын мин, дусларым,*
*Сезгә бирәм, сезнең кулга*
*Тәгәрәсен йомгагым.*

Шәһәребездә яшәүче танылган шагыйрь Мәхмүт Газизовның шигъри йомгагы, менә бик күп еллар инде, сүтелә дә сүтелә. Серле йомгак сүтелгән саен укучы күңеленә матурлык, якты гамь күчә.

Мәхмүт Минәхмәт улы Газизов 1940 елның 8 февралендә Татарстанның Шөгер (хәзерге Лениногорск) районы Туктар Урдаласы авылында колхозчы гаиләсендә туа. 1958 елда Иске Шөгер урта мәктәбен тәмамлагач, Казан педагогия институтының тарих-филология факультетында белем ала. Хезмәт юлын Лениногорск районы Федотовка авылында башлап җибәрә.

КАМАЗ төзелеше башлангач, ул гаиләсе белән Чаллыга күчеп килә. Тулай торакта тәрбияче, төзелештә геодезист, мастер, тимерчелек заводында эшче булып хезмәт куя.

Әдәбииҗатэшенәкилгәндә, Мәхмүт Газизовның тәүге шигырь-хикәяләре мәктәптә һәм институтта укыганда ук район һәм өлкә газеталарында дөнья күрә. Ә 1969 елда яшь шагыйрьнең “Миләш сиртмә” исемле шигырьләр җыентыгы чыга. Шигърият аның гомерлек юлдашына әйләнә. Мәхмүт Газизовны 1978 елда Татарстан Язучылар берлегенә әгъза итеп кабул итәләр. Чаллыдагы әдәби тормышның иң үзәгендә кайнап яшәгән, иҗаты белән танылу тапкан яраткан әдибебезгә күркәм юбилее алдыннан берничә сорау белән мөрәҗәгать иттек.

*— Мәхмүт абый, Сез шәһәребезгә гасыр төзелешенең һәм әдәби тормышның кайнап торган чагында килгәнсез. Романтик рухлы яшьләр җыелган җирдә күңелгә уелып калырлык вакыйгалар күп булгандыр...*

— Әйе, 1970 елның 9 мартында мин Чаллыярга аяк бастым. Шунысы кызык, КАМАЗ белән бер көндә туган кызыма нәкъ өч ай иде. Истә калган хатирәләр бик күп инде. Алар минем шигырьләрдә, очеркларда, газеталарга язган мәкаләләрдә,истәлекләремдә чагылыш тапты. Ул еллар бит бик үзенчәлекле, яшьлек дәрте ташып торган, искиткеч еллар иде. Шәһәребездә “Ләйсән“ әдәби берләшмәсе эшләп килде. Рус теллеләр өчен “Орфей“ гөрләде. Без үзара аралашып яшәдек, иҗат иттек. Тулай торакларда чыгышлар ясый идек. Безнең бик актив Булат Хәмитов, Зөфәр Сәгыйтовларыбыз бар иде. Авылларга барып, мәктәпләрдә кичәләр үткәрдек, терлекчеләр, игенчеләр алдында еш кына имтихан тоттык. Чын мәгънәсендә җыр, шигырь бәйрәмнәре оештыра идек. Казаннан, Мәскәүдән әдәби десантлар төшүе хәтеремдә. Алар белән бер сәхнәдә без — “Ләйсән“ һәм “Орфей“лылар да балкыдык. Болар бик сагындырып искә төшә.

*— Мәхмүт абый, Сез бит инде озак еллар әдәби мәйданда каләм көчегезне сынаган шәхес. Унлап китап авторы. Мәктәпләрдә, балалар бакчаларында да еш кунак буласыз. Сез балалар күңеленә юл салуның серен ачкан шагыйрь дисәм дә ялгышмамдыр, мөгаен.*

— Тәп профессиям буенча укытучы бит мин. Берничә ел татар теле, әдәбияты укыттым. Укыту бүлеге мөдире булып та эшләргә туры килде. Аннары мәктәп директоры булып эшләп алдым. Шуңа да күбрәк балалар өчен язарга тырыштым. Нәни дусларым өчен «Гаҗәеп көн», «Ике куян койрыгы», «Серле ижек» һәм башка китаплар чыгардым. Дөресен әйткәндә, һаман да сакаллы сабый булып яшим әле мин.

*— Күңелендә сабыйлыкны саклап кала алган әдипнең бүгенге яшьләргә дә әйтер сүзе бардыр. Матбугат аша яшьләрнең иҗатын күзәтеп барасызмы, Мәхмүт абый?*

— Без олыгаеп барабыз. Чаллы җирлегендә өметле каләм ияләре юк дип әйтмәс идем. Айгөл Әхмәтгалиева бик өметле күренә. Ул балалар өчен китап та чыгарды. Хикәяләре бик җылы, тәмле, матур тел белән язылган. Сирень Якупова шулай ук бик өметле күренә. Коры лирика гына түгел, ул тормышны киңрәк күзаллый, бик ерак менеп карый. Шулай итеп, иҗади мичкәдә дары бетмәгән әле. Каләмнәре белән очкын кабызырга тиеш чаллылылар.

*— Үткәннәрне хәтерендә яңартып, киләчәккә өмет белән яшәүче өлкән әдибебез Мәхмүт абый Газизов бүгенге көндә нинди иҗат планнары белән яши икән.*

— Билгеле, алда планнар юк түгел. Иң беренче чиратта балалар өчен китап әзерләп чыгаруны күз уңында тотам мин. Һәм соңгы елларда язылган лирик, юмористик шигырьләрне берләштереп, тагын бер китап өлгертергә исәп бар. Монысы инде олылар өчен. Аллаһы Тәгалә саулыктан гына аермасын. Саулык — иң зур байлык. Шуңа өстәп әйтәм, әдәбият, шигърият — рухи байлык, күңел икмәге.

Күңел икмәген башкалар белән бүлешеп яшәүче Мәхмүт абый Газизовны 70 яшьлек юбилее белән барлык каләмдәшләре һәм әдәбият сөюче дуслары исеменнән ихлас котлыйбыз. Аңа барлык теләк-ниятләрен тормышка ашырырлык сәламәтлек, иҗади табышлар һәм игелекле озын гомер телибез.

**Әлфия СИТДЫЙКОВА.**